Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче Кәрәкәшле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«11» ноябрь 2024 ел № 9

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 ноябрендә узган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пункты территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан, тормыш иптәшләреннән), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылганнар гражданнардан тыш, 500 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кәрәкәшле торак пунктында юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Кәрәкәшле торак пунктындагы чишмәне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү (паркларны, скверларны, яр буйларын, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итү өчен бүтән урыннарны) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Кәрәкәшле торак пунктында балалар өчен уен мәйданчыгын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү));
- Кәрәкәшле торак пунктында күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (зират территориясен киртәләү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, койма белән әйләндереп алу (чүп үләннәрен юкка чыгару, корыган агачларны, куакларны кисү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 528 граждан кертелде;

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 270 кеше, бу 51% тәшкил итә.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«Риза» позициясе өчен 270 граждан тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын узган һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пункты территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан, тормыш иптәшләреннән), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылганнар гражданнардан тыш, 500 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кәрәкәшле торак пунктында юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Кәрәкәшле торак пунктындагы чишмәне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү (паркларны, скверларны, яр буйларын, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итү өчен бүтән урыннарны) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Кәрәкәшле торак пунктында балалар өчен уен мәйданчыгын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү));

- Кәрәкәшле торак пунктында күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (зират территориясен киртәләү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Кәрәкәшле торак пунктында күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, койма белән әйләндереп алу (чүп үләннәрен юкка чыгару, корыган агачларны, куакларны кисү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) - соравы буенча гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Для документов
СОВЕТ КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН